**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**КОЗЯКОВО-ЧЕЛНИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422668, с. Козяково-Челны,
ул. Иванова, дом 26

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**КОЗЯКОВО-ЧЕЛНИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422668, с. Козяково-Челны,
ул. Иванова, дом 26

Тел.: (84361) 32310, факс: (84361) 32310, e-mail: Kcn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2021 Казаклар Чаллысы авылы №12

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 2021 елның 30 июлендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 8 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында “агачларның, куакларның һәлакәтлелеге турында бәяләмә белән” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1. пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4. пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1. пунктының 4,5,7 пунктчаларында “Башкарма комитет” сүзен “Башкарма комитет яисә төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы” сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.1. пунктының 6,11 пунктчаларында “Башкарма комитет” сүзен “Башкарма комитет яисә төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы” сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.6.3. пунктында “Башкарма комитетның структур бүлекчәсе” сүзләрен “муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет”сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында “гаризада күрсәтелгән яшел утыртмаларны тикшерү нәтиҗәсендә яшел утыртмаларны (авария хәлендәге агачларны) сүтүнең зарурлыгы расланмау” сүзләрен төшереп калдырырга;
1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында “(авария-торгызу эшләрен башкару белән бәйле яисә яшел утыртмаларны җимерү өчен бик кирәк очраклардан тыш (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен)” сүзләрен төшереп калдырырга;
1.9. 2.8.4 пунктында “2 нче кушымтада” сүзләрен “3 нче кушымтада” сүзләренә алмаштырырга;
1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында “,шулай ук авария-торгызу эшләрен уздыру өчен яшел утыртмаларны кисүгә яисә яшел утыртмаларны җимерү өчен аеруча зарурлык булган хәлдә (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен) рөхсәтнамә алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта)” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3. пунктын төшереп калдырырга;
1.12. 3.5.5. пунктында “;авария-торгызу эшләрен уздырганда яисә яшел утыртмаларны җимерү өчен аеруча зарурлык булган хәлдә (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен) гариза бирүче муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта – ике эш көне” сүзләрен төшереп калдырырга;
1.13. Регламентка 2 нче кушымтада “Авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.” сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Казаклар Чаллысы авылы, Иванов урамы, 26 нчы йорт; Иванай авылы, Калинин урамы,18 йорт; Бирдебәк авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт; Үри Чаллысы авылы, Гаврилов урамы, 24 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы И.С.Ананьев